СОВЕТ СРЕДНЕКИРМЕНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Ленина, д.16А, с. Средние Кирмени, Мамадышский район, Республика Татарстан. 422171

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРТА КИРМӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

Ленин ур., 16А нчы йорт, Урта Кирмән авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422171

тел.(факс): (85563) 2-92-38;2-92-44 e-mail: Skimer.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Решение — Карар

№ 3-7 — «13» апрель 2021 ел

Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советы муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексына үзгәрешләр кертү турында

2008 елның 25 декабрендәге «Коррупциягә каршы тору турында» 273-ФЗ номерлы Федераль Закон, 2007 елның 2 мартындагы «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә», Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт хезмәткәрләренең хезмәттә үз-үзен тотышының гомуми принципларын раслау турында» 2002 елның 12 августындагы 885 номерлы Указы һәм Россия Федерациясе Президенты каршындагы Коррупциягә каршы тору советы Президиумының 2010 елның 23 декабрендәге 21 номерлы утырышы беркетмәсе нигезендә,муниципаль хезмәткәрләрнең этик нормаларын һәм хезмәт тәртибе кагыйдәләрен билгеләү, шулай ук муниципаль хезмәткәрләрнең абруен, гражданнарның җирлеүзидарә органнарына ышанычын ныгытуга ярдәм итү һәм муниципаль хезмәткәрләрнең бердәм тәртип нормаларын тәэмин итү максатларында Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советы

карар кабул итте:

1. Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге Советының 18 апрель 2011 ел, № 4-5 карары белән расланган Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең этика һәм хезмәт тәртибе Кодексына (алгатаба – Кодекс)түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 18 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәр җирлеүзидарә органында гамәлдә булган Россия Федерациясе законнары нигезендә кабул ителгән нормаларны һәм таләпләрне үтәү турында мәгълүматны эшкәртә һәм тапшыра.»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының рәсми http://mamadysh.tatarstan.ru/сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo. tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Мамадыш муниципаль районы Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы Б.Ф.Хасановка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Урта Кирмән авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе /Б.Ф.Хасанов/